**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Важашур авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**11 ноябрь 2020 ел** **№6**

**«Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Яна Каенсар авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Яна Каенсар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яна Каенсар авылы, Гагарин урамы, 14 нче йорт адресы буенча урнашкан фельдшер-акушерлык пункты йорты бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 26 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шенавылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яна Каенсар авылы, Гагарин урамы, 14 нче йорт адресы буенча урнашкан фельдшер-акушерлык пункты йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Яна Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яна Каенсар авылының Гагарин урамнарында вак таш түшәп, юллар төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Яна Каенсар авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Яңа Каенсар авылы зиратында капка алыштыру һәм агачлардан чистарту;
- Яна Каенсар авылында урам яктырткычларын төзекләндерү һәм сатып алу;
- Яна Каенсар авылында балалар мәйданчыгы өчен спорт инвентаре сатып алу һәм урнаштыру: проект-смета документлары;
- Яна Каенсар авылына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Важашур авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Важашур авыл җирлеге башлыгы: П.Л.Иванов